ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-30-61; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«31» октябрь 2019г. № 429

**«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы тарих һәм мәдәни мирас музее» Муниципаль бюджет мәдәният учреждениесенең штат расписаниесенә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 27 июнендәге 584 номерлы "Россия Федерациясе бюджеттан тыш устав капиталында акцияләрнең (өлешләрнең) илледән артык проценты дәүләт яки муниципаль милектә булган дәүләт фондларыннан, дәүләт яки муниципаль учреждениеләрдән, дәүләт яки муниципаль унитар предприятиеләрдән, шулай ук дәүләт корпорацияләреннән, дәүләт компанияләреннән һәм хуҗалык җәмгыятьләреннән файдалану өчен мәҗбүри булган таләпләр өлешендә һөнәри стандартларны куллану үзенчәлекләре турында" карары, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының "“Музей предметларын исәпкә алу буенча белгеч” һөнәри стандартын раслау турында” 04.08.2014 ел, № 521н боерыгы, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 04.08.2014 ел, 537н номерлы «”Музей кыйммәтләрен саклау буенча белгеч” һөнәри стандартын раслау турында” боерыгы, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының “Экскурсовод (ГИД)” һөнәри стандартын раслау турында " 04.08.2014 ел, №539н боерыгы, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының "“Программист” һөнәри стандартын раслау турында" 18.11.2013 ел, № 679н боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы тарих һәм мәдәни мирас музее» Муниципаль бюджет мәдәният учреждениесенең штат расписаниесенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1.1. Штат расписаниесеннән түбәндәге берәмлекләрне чыгарырга:
- методист;
- фондларны саклаучы;
- эшче;
- җыештыручы;
- 0,5 ставка каравылчы.

1.2. Штат расписаниесенә түбәндәге берәмлекләрне кертергә:

- музейның фәнни хезмәткәре;
- 1 категорияле музей предметларын саклаучы;
- биналарга һәм корылмаларга комплекслы хезмәт күрсәтү буенча эшче;
- биналарга һәм корылмаларга комплекслы хезмәт күрсәтү буенча эшче 0,5 ставка;
- хезмәт урыннарын җыештыручы.

2. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Р. Р. Гыйльметдиновага йөкләргә.

**Җитәкчесе** **А. С. Авдеев**